ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ИННОПОЛИС» ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ГРАЖДАННАРНЫҢ КЫРЫГЫНЧЫ ҖЫЕНЫ

3нче номерлы карар

2019 елның 26 ноябре Иннополис шәһәре

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының
«Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлегенең генераль
планын раслау турында

Территориянең тотрыклы үсешен, инженерлык, транспорт һәм социаль инфраструктураны үстерүне, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 9, 24, 25 статьялары,«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 10 статьясы, «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлегенең генераль планына үзгәрешләр кертү проекты буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының уңай бәяләмәсен исәпкә алып, «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлегенең генераль планына үзгәрешләр кертү проектын, шулай ук ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәне исәпкә алып

«ИННОПОЛИС ШӘҺӘРЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ ХАЛЫК ҖЫЕНЫ
КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлегенең генераль планын расларга (Кушымта).
2. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге гражданнарының «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлегенең генераль планын раслау турында» 2015 елның 25 сентябрендәге 4нче номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Югары Ослан муниципаль районының Интернет (http://verhniy-uslon.tatarstan.ru/) мәгълүмат сайтында, шулай ук Иннополис шәһәре мэриясе бинасында урнашкан махсус мәгълүмат стендында урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Рәислек итүче,
Иннополис шәһәре мэры Р. Р. Шагалиев